ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы,
Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

СОВЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора,
Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

КАРАР **РЕШЕНИЕ**
7 август 2019 ел **№ 307**

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районында бюджет процессы турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы (2019 ел, 6 нчы июньгә үзгәрешләр белән), РФ Кодексы, 1998 ел, 31 нче июль, 145-ФЗ, "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында", 2003 ел, 6 нчы октябрь, 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Биектау муниципаль районы Уставы белән эш йөртеп, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советы,

КАРАР ИТТЕМ:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советының 2019 ел, 17 нче апрель, 279 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районында бюджет процессы турында Нигезләмәнең 16 статьясы 4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"4. Әлеге статьяда күрсәтелгән субсидияләрне тәкъдим иткәндә, субсидияләр бирү турында шартнамәләргә (килешүләргә) һәм (яки) норматив хокукый актларга, аларны җайга сала торган муниципаль хокукый актларга, һәм әлеге шартнамәләр (килешүләр) буенча йөкләмәләрне башкару максатыннан төзелгән шартнамәләргә (килешүләргә) кертелә торган аларны бирүнең мәҗбүри шарты булып, субсидияләрне алучылар һәм шартнамәләр (килешүләр) буенча товарлар җитештерү (урнаштыру), эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү (дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләрдән, хуҗалык ширкәтләре, устав (җыелма) капиталларында гавами-хокукый берлекләр катнашындагы җәмгыятьләрдән, шулай ук устав (җыелма) капиталларында әлеге ширкәтләр һәм җәмгыятьләр катнашында коммерцияле оешмалардан кала) белән бәйле чыгымнарны финанс тәэмин итүгә субсидияләр бирү турында шартнамәләр (килешүләр) буенча йөкләмәләрне башкару максатыннан төзелгән шартнамәләр (килешүләр) буенча тәэмин итеп торучыларның (подрядчы, башкаручы), субсидияләр биргән бюджет чараларын төп бүлүче (бүлүче) һәм дәүләт (муниципаль) финанс контроле тарафыннан субсидияләр бирүнең шартларын, максатларын һәм тәртибен тотуны алар тарафыннан тикшерүгә рөхсәтләре тора."

2. Әлеге карар Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы http://pravo.tatarstan.ru/ веб-адресында, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Биектау муниципаль районы рәсми сайтында

Интернет мәгълүмат-телекоммуникацияләр челтәрендә http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адресы буенча урнаштырып халыкка җиткергәннән соң үзенең законлы көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Биектау муниципаль районы Советының бюджет, финанслар һәм икътисади сәясәт буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет Рәисе,
муниципаль район Башлыгы Р.Г.Кәлимуллин